

Кадошкино районы Латышовка авылында гомер итүче Әминә Хәсән кызы Саитовага, 90 яшь тулу унаеннан, Президентыбыз В.В.Путин котлавы килгән. Ә котлауда – язмышыннан юллар.

Гади авыл кешесе язмышы. Әминә Хәсән кызына, Боек Ватан сугышы башлангач, унсигез яшь тула. Бу буын кешеләренә күпне күргә, күпкә чыдарга туры килә. Яшьли калганнар тылда да жафа житәрлек күрә. Коне буе фронтка ипи үстерү, жыю, ә кичләре тагы хезмәт белән бергә үткән. Урманнан агачларны ой алдына китергәч, түндәкләргә пила белән пилить итүләр, ә аннары чурка ярулар – барысы аларнын кичке хезмәт списогында була. Норманны үтәгәч кенә йокларга ятарга туры килгән. Иртән, топ хезмәткә киткәнче, шул чуркаларны арбага тояп озатканнар. Әминә Хәсән кызы истәлекләреннән. «Урман да кисәргә туры килде, - дип хәтер капчыгын сүтә ул. Күпне күрдек, безне жәлләүче булмады. Яшь башым белән атлар да карадым... Сугыш тәмамланды, әмма безнен эш бетмәде. Латыштан, 37 кешелек бригада тозеп, Смоленщинага озаттылар. Эш күп, ә сугыштан сонгы чорда эшләргә кеше аз, шуна торле яклардан жыелып эшләдек бу жирләрдә. Мин аш пешердем. Ә ойгә кайткач, фермабызда сыер савучы булып хезмәт юлымны дәвам иттердем. Шунда лаеклы ялга кадәр эшләдем. Шулай туган авылымда гомерләр эштә үтте, нәкъ Президентыбыз котлау хатында язганча.

Гаилә кордык, ирем – «алтын кеше» иде. Мин тормышым белән бик тә канәгать. Хезмәтчән һәм гади булды Зәкәрьям. Анын белән икәү дүрт бала тәрбияләп үстердек. Онык чаларыбыз инде безне шатландыралар. Тормышка рәнжер хәлем юк. Шатлыклар һәм югалтулар очен рәхмәтлемен! Шуна ул тормыш диелә. Бүгенге яшәеш әйбәт; яшә һәм шатлан, ялкауланмый эшли генә бел. Лаеклы пенсия алабыз, вакытында китереп бирәләр.

Авылыбыз үсә, матурая, яшьләр күп, мәктәбебез яхшы, яна ФАПыбыз. Һәрбер кешенен оенә суы кертелгән, газ белән ягыла; жылы, якты. Карт кешегә тагы ни кирәк! Тиздән сайлаулар, мин башланган эшләрнен унышлы тәмамлануы, тыныч тормыш очен тавышымны бирәчәкмен. Бүгенге Ватаныбызны кочле һәм бәйсез күрәсе килә», - ди 90 яшен тутырган юбиляр Әминә Хәсән кызы Саитова.

Әминә Хәсән кызы матур йортта кызы Надия белән яши. Картлыгы ышанычлы кулларда. Уллары да еш әниләренен хәлен белергә киләләр. Бер сүз белән әйткәндә, авыр хезмәттә үткән гомере матур картлыкта уза.

«Әниемнен күнеле һәрвакыт изге-лектә булды; барча кешегә һәм һәрбер нәрсәгә, - дип остәп куя Әминә Хәсән кызы Саитованын кызы Надия. – Мин белгәнчә, ул һәрвакыт

гаиләсе турында кайгыртты, гомере хезмәттә үтте. Без йокларга яткanда әле аяк остендә булды, иртән торганда – һаман аяк остә булуы хәтеремдә. Шуна да без Әниебезне кадер-хормәттә яшәтергә тиешбез. Лаеклы ялы рәхәттә үтсен. Безнен очен һәрвакыт янган йорәге тыныч булсын. Барыбызны шатландырып озак яшәсен иде кадерлебез!»

Кремльдан Латышовка авылы гади хатынына, Әминә Хәсән кызы Саитовага, 90 яшьлек юбилеена килгән котлауда шатлыклы озын гомер теләнгән иде.

Н.Хәлил